**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль район Советы**
**КАРАРЫ**

**2021 елның 1 июле** **№ 51**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2018 елның 27 августындагы 148нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына территорияләрне комплекслы үстерүне тәэмин итү максатларында үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 494-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 7 пункты, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ**:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2018 елның 27 августындагы 148 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 2 өлешендәге 6 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

2) 12 статьяда: өченче абзацта «, әлеге статьяның дүртенче абзацында билгеләнгән очраклардан тыш,» сүзләрен өстәргә; түбәндәге эчтәлекле яңа дүртенче абзац өстәргә:

«Территорияне комплекслы үстерү турындагы карар кабул ителүгә бәйле рәвештә җирлекнең генераль планына үзгәрешләр әзерләнгән очракта, иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә үткәрелергә мөмкин.»;

дүртенче, бишенче һәм алтынчы абзацларны бишенче, алтынчы һәм җиденче абзацлар дип санарга.

3) 13 статьяны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (kamskoye-ustye.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы башлыгы урынбасары Г.Ә. Габидуллинга йөкләргә

**Кама Тамагы муниципаль районы Башлыгы,**
**Кама Тамагы муниципаль район Советы рәисе Н.А.Вазыйхов**